СУБСИДИЯЛӘР АРТАЧАК
Кемнәргә тиеш?
> 2

МИЛЛИ МӘСЬӘЛӘ
Буада тел язмышы турында сөйләштеләр
> 2

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК
«ВТ» укучыларының күңелендә сакланган хатирә-истәлекләре
> 3

ЯКТЫЛЫККА ТАБА
Татар театрлары яңа сезонда ниләр күрсәтәчәк?
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 132 (28905) | Шимбә | 10 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ОТЫШЛЫ ЯЛ

КЕШБӘК ПРОГРАММАСЫ НИДӘН ГЫЙБАРӘТ?

«Фәлән әйбер сатып ал да кешбәк кайтар!» Моның ише игъланнарны ишетергә ияләшеп беттек инде. Баштарак колак өчен шактый ят тоелган «кешбәк» сүзенең түләгән акчаның бер өлешен кире кайтару икәнен дә күптән аңладык. Рәтен генә белеп бетермибез.

Кием-салым, көнкүреш техникасы, билет, ял итү турлары, балалар лагерена юллама... Бүген кешбәк кайтарып булган хезмәтләр исемлеге бихисап. Бу хезмәт елдан-ел популярлаша бара. Әйтик, узган ел Татарстанда ата-аналар кешбәк программасы буенча балалар лагерена 36 мең юллама сатып алган һәм 400 миллион сум чамасы акчаны кире кайтарган. Моның өчен юлламаны privetmir.ru порталында теркәлгән «Мир» картасы ярдәмендә сатып алырга гына кирәк. Аннары ата-анага бу акчаның яртысы кешбәк буларак кире кайтачак.

Туризм тармагында бу төшенчә аеруча популяр. Арчада яшәүче Илнур Гарипов күптән түгел генә Калининградта ял итеп кайткан. 5 көн һәм 4 төннән торган 14400 сумлык сәфәр өчен аңа 2880 сум акча кире кайткан. «Кибеттән әйбер сатып алганда кешбәк кайтарганым булса да, ял өчен акчаның кире кайтканы юк иде әле. Бик отышлы икән. Балтийск, Светлогорск шәһәрләрендә, гәрәбә комбинаты, «Бии торган урман»да булып, рәхәтләнеп ял итеп кайттык. Үзебездә дә менә диген итеп ял итеп була хәзер», – ди ул.

«Туту.ру» порталы мәгълүматларына караганда, быел көз ил халкының 30 проценты кешбәк программасы ярдәмендә сәяхәт итәргә җыена. Шуларның 18 проценты бу мөмкинлектән беренче тапкыр файдаланып караячак. Россия халкы көзге-кышкы чорда, нигездә, Сочи, Мәскәү, Санкт-Петербург, Калининград, Махачкала, Красноярск, Екатеринбург, Казан һәм Новосибирск шәһәрләренә сәфәр кылырга җыена, ди белгечләр.

Билгеле булганча, туризм тармагында кешбәк программасы өченче ел рәттән эшли. Ул Россия буйлап сәяхәт иткән кешегә сәфәр яки кунакханә өчен «Мир» картасы белән түләгән очракта шактый акчаны янга калдырырга ярдәм итә. Программа эшли башлаган көннән бирле аннан барлыгы 4,3 миллион кеше файдаланган.

Көзге һәм кышкы чорга кешбәклы турлар 25 августта ук сатыла башлады һәм 10 сентябрьгә кадәр дәвам итте. Бу мөмкинлектән файдаланган кешеләр 1 октябрьдән 25 декабрьгә кадәр Россия буйлап сәяхәт кылганда сарыф иткән акчаларының 20 процентын кире кайтара алачак.

Моның өчен иң элек «Мир» картасын лояльлек программасында (privetmir.ru) теркәргә кирәк. Алга таба үзегез сайлаган турны шушы ук карта белән түлисе булачак. Бу акча сезгә биш көн эчендә кире кайтачак. Дөрес, сәяхәт өчен түләгән акчаның бер өлешен кире кайтарып булсын өчен, берничә шарт үтәлергә тиеш. Иң беренче чиратта кешбәк программасы буенча сайланган турның 25 августтан 10 сентябрьгә кадәр алынган булуы шарт. Сәфәр ким дигәндә 4 көн һәм 3 төн дәвам итәргә тиеш. Кешбәк программасы 1 октябрьдән 25 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк сәфәрләргә кагыла.

pixabay.com

Башкаладагы билгеле туризм агентлыгы белгече Алия Сабирова туризм тармагындагы кешбәк программасын соңгы елларда бу тармакка кертелгән иң отышлы яңалыкларның берсе дип саный.

– Үзебезнең ил буйлап сәяхәт итәргә җыенган кешегә бу программа буенча тур эләктереп калырга тырышырга кирәк. Шактый акчаны янга калдырып була бит. Мисал өчен, Россия халкының иң яраткан урыннары саналган Пятигорск һәм Кисловодскида 3 төн куныг, 4 көн сәяхәт итү бүген 19995 сумга төшә. Кешбәк программасы буенча бу акчаның 3999 сумы кире кайтачак. Шулай ук Төньяк Осетиягә 16 мең сумлык турның 3216 сумы кире кайтачак, – ди Алия Сабирова.

Әмма шунысы бар: бу программа буенча кайтарылган акча күләме 20 мең сумнан да артмаска тиеш. Әйтик, сез 120 мең сумга Алтайга ике кешелек тур алдыгыз ди. Бу бәягә юл чыгымнары, кунакханәдә биш көн яшәү кергән. Тур хакының 20 проценты 24 мең сумны тәшкил итсә дә, кешбәк программасы буенча сезгә барыбер 20 мең сум акча кайтачак. Бу программада Ерак Көнчыгышка сәфәргә җыенучыларга гына искәрмә ясала. Аларга 40 мең сумга кадәр кешбәк кайтачак.

Сүз уңаеннан, бүген күпләр махсус кешбәк карталары да куллана. Әмма белгечләр аны рәсмиләштергәндә бик игътибарлы булырга киңәш итә. Финанс белгече Булат Гарифуллин сүзләренә караганда, тагын кайбер нәрсәләргә игътибар итәргә кирәк. «Бу картаны тәэмин итеп торган өчен банк комиссия алырга, кешбәк исә билгеле бер төр чыгымнар, әйтик, машинага ягулык салганда түләгән акчадан гына кире кайтарылырга мөмкин. Әгәр сез бу хезмәт өчен карта белән түләмәсәгез, сезгә бернинди акча да кире кайтмый. Ә айлык комиссияне барыбер түләргә туры киләчәк. Шул рәвешле кешбәк картасының бернинди файдасы да калмый булып чыга», – ди белгеч.

Көзге сәүдә гөрләячәк

Бүгеннән Татарстанда көзге ярминкәләр башлана. Алар 24 декабрьгә кадәр һәр шимбә саен оештырылачак. Казанда сәүдә шәһәрнең һәр районында – барлыгы 15 мәйданчыкта иртәнге 6дан көндезге 12гә кадәр гөрләячәк.

Ярминкә урыннарында Министрлар Кабинеты Ветеринария идарәсе белгечләре кизү тора. Идарәдә билгеләп үтелгәнчә, барлык ит, балык һәм сөт ризыклары сатуга тиешле ветеринария документлары нигезендә генә кертелә. Азык-төлекнең сыйфатын лаборатория хезмәткәрләре тикшерә. Сыйфатсыз продукция кире борыла.

Фермерлар шәһәр халкын чагыштырмача арзан бәядән сыйфатлы азык-төлек белән тәэмин итәчәк. Ярминкәләрдә ит, яшелчә, башка продукция, шулай ук ярдәмче хуҗалык кирәк-яраклары сатып алырга мөмкин. Казанның һәр сәүдә мәйданчыгында Татарстанның 22 районы, шулай ук 18 агрокомплекс оешмасы продукциясе сатылачак.

Үзмәшгульнең – үз ярминкәсе

Быел Татарстанда үзмәшгульләр «Шәхси эшмәкәрлек башлангычына ярдәм итү» илкүләм проекты буенча оештырылган ярминкәләрдә 16 миллион сумнан артыграк акча эшләгән. Икътисад министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, быел мондый ярминкәләрдә 800дән артыграк үзмәшгуль катнашкан. Аларга сәүдә урыннары бушлай бирелгән. Үзмәшгульләр анда үзләренең продукциясен: агачтан, тиредән эшләнгән әйберләр, фарфор савыт-саба, бизәнү әйберләре, уенчыклар, йорт кирәк-яраклары, фермер продукциясе саткан, шулай ук юридик, полиграфия, белем бирү хезмәтләре белән таныштырган.

Моннан тыш Татарстанда үзмәшгульләрнең иң озын – 245,5 метрлы сәүдә киштәсе буенча Россия рекорды куелган. Республика көнендә 300дән артыграк кәсепче катнашындагы ярминкәдә теркәлгән ул. Шул ук вакытта үзмәшгульләрнең керем күләме дә, рекордлы күрсәткечкә җитеп, 4 миллион сумнан артып киткән.

Республика үзмәшгульләре ярминкәләре инде 4 ел рәттән үткәрелеп килә. Киләсе ярминкә 17–18 сентябрьдә уздырылачак. Анда катнашучыларга Фәннәр академиясе янындагы махсус җиһазландырылган мәйданчыкта бушлай урыннар бирелә.

«Татар-информ» / Михаил Захаров

Сайлау – 2022

Аклансын өметләр

11 сентябрьдә Россия төбәкләрендә сайлау узачак. Кайсыларында халык – башлык, кайсыларында депутат сайлый. Шул исәптән Татарстанда да Дәүләт Советына өстәмә сайлау кампаниясе булачак. Республика бердәм тавыш бирү көненә әзерме? Сайлау хокукына кемнәр ия? Сәяси ярышта кемнәр катнаша?

Татарстанда ничек?

Бу атна якшәмбесендә Казанда 7 номерлы Ибраһимов һәм 14 номерлы Пионер бер мандатлы округлары буенча Дәүләт Советына өстәмә сайлау узачак. Тавыш бирүдә 123,1 мең кеше катнаша ала. Бу – республикада яшәүчеләрнең 4 проценты. Сайлауны 2 территориаль һәм 53 участок сайлау комиссиясе оештыра.

Сәяси ярышта 12 кеше катнаша. Үз кандидатларын җиде сәяси партиянең төбәк бүлекчәләре тәкъдим итте. Бу – биш парламент партиясе («Бердәм Россия», КПРФ, ЛДПР, «Справедливая Россия – Патриоты – За правду», «Новые люди») һәм парламентка кермәгән ике («Партия Роста» һәм «Коммунисты России») партия. Республика парламентына ике мандатның һәрберсенә 6шар кандидат дәгъва кыла. Быелгы сайлау кампаниясендә катнашучы кандидатларның уртача яше – 40. 25 проценты – хатын-кыз кандидатлар.

ЧАГЫШТЫРУ ӨЧЕН



- 2019 елгы Дәүләт Советына сайлау: 100 урынга – 430 кандидат.
- 2020 елгы муниципаль сайлау: бер урынга – 3 кеше.
- 2022 елгы өстәмә сайлау: бер урынга – 3,5 кеше.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ил буенча төрле дәрәҗәдәге 4700 сайлау участоклары эшли. 22 сәяси партиядән барлыгы 70500 кандидат теркәлгән.

Моннан тыш, бердәм тавыш бирү көнендә Татарстанның 39 районындагы 181 округта җирле үзидарә органнары депутатларын өстәмә сайлау узачак. Тавыш бирүне 42 территориаль һәм 177 участок сайлау комиссиясе оештыра. Сайлаучылар саны 51,2 мең кешене тәшкил итә. Җирле үзидарә органнарына депутатлыкка кандидат буларак 670 кеше теркәлгән. Аерым алганда, ЛДПРдан – 178, «Справедливая Россия – Патриоты – За Правду» – 142, «Бердәм Россия» – 108, КПРФ – 29, «Партия Роста» – 5, «Коммунисты России» – 2, «Новые Люди» – 1, «Татарстан – Яңа Гасыр» иҗтимагый хәрәкәтеннән 3 кеше сайлауда катнаша. 202 кеше үз-үзен тәкъдим итүче булып теркәлгән.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Диана ГАБДЕЛГАНИЕВА, Татарстанның баш терапевты:

Социаль хезмәтләр программасында калучылар асылда үз сәламәтлеген иминиятләштерә. Шикәр чиреннән яки югары кан басымыннан интегүчеләрдә диспансеризация вакытында башлангыч стадиядәге яман шеш тә ачыкланырга мөмкин бит. Ә бу инде амбулатория этабында бөтенләй башка чыгымнар таләп итә. Шуңа күрә дәүләт биргән мөмкинлекләрдән файдаланырга кирәк.

(«Татар-информ»)

РОССИЯДӘ – COVID-19

Коронавируска каршы көрәш буенча оператив штаб чир таралуга бәйле соңгы мәгълүматлар белән уртаклашты.

ТАТАРСТАНДА
- **689** очрак
- **314** кеше сәламәтләнгән
- **93** кеше хастаханәгә салынган

РОССИЯДӘ
- **52106** очрак
- **51086** кеше сәламәтләнгән
- **3621** кеше хастаханәгә салынган

Исерек айнысын

Ел башыннан бирле полиция хезмәткәрләре 9 меңнән артыграк сәрхуш йөртүчене тоткарлаган. ЮХИДИ идарәсе башлыгы Рөстәм Гарипов әйтүенчә, 715енең инде моңарчы да эләккәне булган.

Исерек йөртүчеләр турында 02 һәм 112 телефоннары, шулай ук ЮХИДИнең телеграм-каналлары аша хәбәр итәргә мөмкин. Салган баштан рульгә утырган 65 кеше нәкъ менә шундый хәбәрләр нигезендә тоткарланган.

Салкын булса да, куркыныч

Татарстан урманнарында янгын куркынычы гадәттән тыш зур булу сәбәпле, куркыныч турында кисәтү янә озайтылган. Сентябрь башыннан икенче тапкыр озайту инде бу. Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, 10–16 сентябрь аралыгында Татарстанның көнбатыш районнарында урыны белән гадәттән тыш зур дәрәҗәдә (V класс) янгын куркынычы сакланып кала.

Шулай итеп, урманнарда янгын куркынычы турында кисәтү җәйдән бирле барлыгы алтынчы тапкыр озайтылган инде. Татарстанда ул 28 июльдән игълан ителде һәм берничә тапкыр озайтылды.

Республикада янгын куркынычы зур булу сәбәпле, 29 августтан урманнарга керү кабат чикләнгән. Чикләү 21 көн гамәлдә булачак.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Тарату җыюдан җиңел

Олы пароход үзе яңгыраткан музыка җаена акрын гына причалдан аерыла, ачык диңгезгә чыгарга әзерләнә. Андый чакта, гадәттә, китүчеләр палубаны сырып ала, һәммә кеше, хушлашып, кул болгый, күзләр ярга текәлгән. Пароход озын итеп сузып кычкырткан мәлдә, причалда калган озатучылардан кемдер кулындагы эшләпәсен баш өстендә уңга-сулга йөртә, хатын-кызның кайберләре яулыгын салган, шуны җилпи. Хәтсез күзләр дымлы, йөзләр гадәттән тыш моңсу. Китүчеләрнең бераздан әйләнеп кайтасын, иртәмесоңмы күрешү шатлыгы кичерәсен белгәндә дә мондый сурәт шактый тәэсирле. Ә хушлашу гомерлеккә, мәңгегә булса?

Моннан нәкъ йөз ел элек, 1922 елның сентябрендә Петроград портыннан Германиягә китүче пароход нәкъ менә туган илгә беркайчан да кире кайта алмаячак халык белән шыплап тулган була. Билгеле галимнәр, табиблар, инженерлар, исемле язучылар, философлар. Алар гомер иткән илләре белән хушлаша, соңгы тапкыр таныш ярларга бага. Ул чорларда пароходлар, кузгалган мәлдә, нинди музыкаль әсәрләр уйнаткандыр, әйтү авыр. Без бәян иткән очракта Огинскийның «Ватан белән хушлашу» дип аталган, тәндә бала йоннары кабарта торган мәшһүр полонезын уйнату урынлы булгандыр, бәлки.

Китүчеләрне газиз Ватаныннан бөтенләйгә аерган ул көздә юлга кузгалган дүрт судноның һәрберсен соңыннан «философик пароход» («философский пароход») дип атаячаклар. «Атарга сәбәп юк, илдә калдырырга да ярамый». Тагын җиде елдан үзе дә читкә сөреләчәк Лев Троцкий ул көздә шулай дип белдерә.

«Философик пароход»ка тутырылган йөзләгән кешенең (алар арасында соңрак вертолет уйлап тапкан Сикорский, телевидениегә нигез салучы Зворыкин, философлардан – фикерләрен Путин кабатларга яраткан Иван Ильин, Николай Бердяев, Семен Франк, Сергей Трубецкой, башкалар) кайгы-көенечләрен, ихтимал, сөйләп бетерерлек булмагандыр. Тик алар соңыннан сөенгәндер, дип уйларга да нигез бар. Чөнки алар туыпүскән илдә бик тиздән «ышанычсыз»лар исемлеген, куудан бигрәк, атып үтерү өчен төзи башлыйлар. Әйе, революция, «кызыл террор», яңарак кына тәмамланган гражданнар сугышы – заманы шундый булган, инде нишләтәсең, дияр кайберәүләр. Янәсе, артык кәнфитләнер чак түгел. Юк, андый караш белән һич килешеп булмый. Шул исәптән куу белән дә. Җинаятьне заманга, чорга сылтау үзе җинаятькә тиң.

Куылучыларның илгә, яңа властька ни зыяннары тигән соң? Гаепләре шул: алар яңа режимга, хәзергәчә әйткәндә, лояльлек күрсәтмәгән, аның гамәлләрен хупламаган. Ә яңа хакимиятнең мантыйгы гади: «Кем безнең белән түгел – шул безгә каршы». Илнең, милләтнең каймагын, сәләтле кешеләрне, фикер ияләрен, башкача уйлыйлар, дип кенә шулай читкә аткаруда шул дуамал принцип яткан. Яңа тормышны «черек интеллигенция»сез генә төзиселәре килгән. Ул вакытта «кеше капиталы» дигән төшенчә, теләсә кайсы дәүләтнең беренче байлыгы – аның кадрлары, сәләтле һәм әзерлекле белгечләре, фикерле кешеләре икәнлекне аңлау булмаган, дию хата булыр иде. Тик «сыйнфый дошман» төшенчәсе, күрәсең, яңа властьның аңын томалаган. Башкача ул затлы кешеләрнең үз илен – Россияне күтәрәсе, аны данлы итәсе урында гел башка дәүләтләрне баетачагын, мәгърифәтле, гыйлемлерәк итәчәген күрмәүне ничек аңларга? Сөйләшәсе, килешәсе, эшләр шартлар тудырасы урында, пароходка дыңгычлап тутырып, читкә сөрер өчен тилемсә идеяләрнең акылдан өстенлеге кирәктер ул.

XX гасыр тарихында, «философик пароход»лар чорыннан тыш та, ничә дулкын эмиграция бар. «Ник биредә шундый полярлашкан акыл һәм аңа буйсынган гамәлләр соң?» – дип сорыйсы килә кайчак. Ник «ак» һәм «кара» гына? Башка дәүләтләр сәләт ияләрен, затлыларны кочак җәеп каршы алганда, зурлаганда, җыйганда, биредә ник андыйлардан котылу, аларны тарату җаен караганнар? Кумаган, мәҗбүриләмәгән тәкъдирдә дә кеше үзе төенчекләрен төйнәсен, чемоданына ябышсын өчен, мантыйкка сыймас эшләр кылынган бит. Китүчеләрне гыйлем, фикер ияләре, дип атамаган җәһәттә дә, алар, гадәттә, үз-үзенә ышанган булдыклы, гаярь кешеләр булган. Андый катлауның һәм дә «философ»ларның китүе ул бит – зурдан алганда, илдә пассив һәм мокыт соры масса күбәюгә, хәтта, әйтер идем, гыйбадлашуга юл…

Шушы атна уртасында Росстат сайтында 2022 ел башыннан илдән 419 мең кешенең китүе турында рәсми мәгълүмат чыкты. Статистика киметеп күрсәтмәгән очракта да сан зур. Киткәннәр урынын өлешчә барыбыз да белгән гастарбайтерлар – Урта һәм Үзәк Азия ягыннан килгән, биредә төпләнү ягын караган «кара эш»кә хирыс «кара халык» ала, дию дә хата булмас. Илебезне «икенче дөнья»га керткәндә, без асылларыбызны «беренче дөнья»га озатып, «өченче дөнья» вәкилләрен үзебезгә сыендырабыз булып чыга.

XX гасыр «Россия» дигән ил өчен үтә дә михнәтле булды, дию Америка ачу түгел. Тетрәнүләрне без кайчакта үзебез үк тартып китерәбез кебек. Маркс теориясе, мәгълүм «Манифест»та ул язган «коммунизм шәүләсе» башка тарафларда түгел, нәкъ менә Россиядә материальләште, күп санлы бәлаләр сәбәпчесе булды. Теләсә нинди глобаль бәла – күченү, миграция, «философик пароход» дигән сүз. «Ак эмиграция» дип аталган беренче дулкын 1917 елдан соң ук туган булса, 1990 нчы елларда башланганы әле бүген дә дәвам итә. «Утечка мозгов» дигәндә, ул инде хәзер «акылы башына сыймаган» философлар гына түгел. Төрле чыганаклар 1990–2000 еллар арасында 1,8 миллион кешенең Россия белән хушлашуын әйтә. Соңгы 20 елга килгәндә, саннар төрлечә. Ләкин аларның да иң өметле дигәне – ике миллионнан өстә. Андыйлар арасында станок артында металл кыручылар, сатучылар, сантехниклар юк диярлек. Анда илгә кирәкле, киләчәктә аны баерак, абруйлырак, иреклерәк итәргә сәләтле кешеләр…

Бәндә чемоданга үрелмәслек җәмгыять, зыялы, гыйлемле, мөхтәрәм затлар һәммәсе биредә ябышып ятарлык, ул гынамы, башка илләрдәге белгечләр дә бирегә тартылыр, шундыйларны җыярлык шартлар, система, вазгыять тудырасы иде…

ҮТЕМЛЕ СҮЗ

БУАДА ТЕЛ ЯЗМЫШЫ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

Милләт

«Татарча сөйләшмәвебезгә рус теле түгел, үзебез гаепле. Телебезне үзебез аяк астына салып таптыйбыз. Беренче чиратта үзебез үрнәк күрсәтергә тиеш». Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясенең Буада узган киңәшмәсендә комиссия җитәкчесе, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов әнә шулай диде.

buinsk-tat.ru

Киңәшмәдә Идел аръягы районнары башлыклары, мәгариф, мәдәният идарәләре җитәкчеләре катнашты. Кунаклар башта районның Исәк авылында булды. Бетүгә таба барган авылны саклап калу өчен нинди эшләр башкарылган? Биредә ябылган мәктәп урынында тегү цехы оешкан. Авылның зур мәчете, кибете, гаилә фермалары да бар. Салага яңа сулыш өрүдә авылдашлары, Казандагы Буа якташлыгы җәмгыяте башлыгы Ирек Закиров зур хезмәт куйган.

– Үз авылын саклап калу өчен Ирек Закиров бик матур гамәлләр башкарган. Бу – бик матур үрнәк. Авыл – туган телебезнең нигез ташы. Кызганыч, авылларның бүгенге халәте аларның киләчәген бик өметле итми. Авылларыбызның ныклыгын, халык санын, яшьләрне күп еллар дәвамында әкренләп югалта килдек. Мөмкин булган бөтен чаралар белән аларның яшәешен сакларга иде. Бу – министрлык, хәтта республика көченнән генә килә торган гамәл түгел. Ил күләмендә күтәрелеп, моның буенча махсус бер колачлы, киң программа булса, авылларны саклап калып булыр иде, – диде Марат Әхмәтов утырышта.

Ул үзе җитәкләгән ике ел эшләп килүче комиссия эшчәнлеге турында сөйләде.

– Телне саклау мәсьәләсенә җәмгыятьчелекнең, милләттәшләребезнең, хакимиятнең, төрле дәрәҗәдәге структураларның игътибарын җәлеп итә алдык, дип саныйм. Күңел төшенкелегенә бирелмичә, безгә бу эшне дәвам итәргә кирәк. Бу – кылыч болгап, йодрык сугып түгел, бик нечкә һәм аңлашып кына башкара торган эш. Биредә, һичшиксез, безнең милли җәмәгатьчелегебезнең, интеллигенциянең дә активлыгы кирәк. Туган телләребезнең язмышы бик күп факторлардан тора. Беренчесе, әлбәттә – гаилә, әти-әни. Икенчесе – милли мәгариф, аннары дин һәм әхлак, милли мохит. Шушы юнәлешләрдә үзебезгә эш табып, рухи бушлыкны тутырырга тырышып эшләсәк, без, һичшиксез, телебезнең гомерен озынайта алабыз, – диде ул.

Буа районы башлыгы Ранис Камәртдинов районда төрле милләт вәкилләренең бер-берсенең туган телләрен, гореф-гадәтләрен, милли кыйммәтләрен өйрәнеп яшәве турында әйтте. Үз чыгышында милли мәгариф мәсьәләләренә дә кагылды.

– Һәр әти-әни баласы белән татарча сөйләшсен, һәр гаиләдә татар теленә урын булсын иде. Телнең матурлыгын, бөеклеген, көчен, мәгънәсен без һәрвакыт балага төшендереп торырга тиеш. Чөнки халкыбызның гореф-гадәтләре, традицияләре, тарихы туган телебезгә бәйле. Буа районы – барлык милләтләрнең байлыгын саклаган төбәкләрнең берсе, – диде район башлыгы.

Марат Әхмәтов Буага таләпләр һәм бурычларның һәрчак югарырак куелып килүе турында искәртте.

– Ул киләчәктә дә шулай булачак. Буа үзенә күрә Идел аръягының башкаласы санала. Аңа үзенең күпкырлы тормышы белән бөтен күрше-тирә районнарга үрнәк булу бурычы куелган. Бүген район шундый булырга тырыша да, – диде ул.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе җитәкчесе Лилия Әхмәтҗанова быел төп игътибарның балалар бакчаларына һәм башлангыч сыйныфларга биреләчәген әйтте.

– Бакчалар – милли мәгарифнең нигезе. Халкыбызда «Алтыда белгән ана телең алтмышта онытылмас» дигән гыйбарә яши. Мәктәпкәчә чор – балаларга тел өйрәтүнең иң нәтиҗәле чоры. Шуңа күрә бакчаларда балаларыбызны саф татар телендә сөйләшергә, фикерләргә өйрәтү – иң изге бурычларның берсе. Бакча мөдирләре, тәрбиячеләре белән актив эш оештыруны сорыйбыз. Барысы да җитәкчедән, аның милли мәгарифкә булган карашыннан башлана, – диде ул.

Лилия Әхмәтҗанова быел мәктәпләрдә татар телен дәүләт теле буларак укыту мәсьәләләренә дә тукталды.

– Бу – безнең өчен яңалык түгел. Без гомер-гомергә татар телен өч программа белән укыттык. Программа да, дәреслекләр дә сакланды. Татар телен дәүләт теле буларак кына өйрәнү ул – татар телен белмәгән, татар милләтеннән булмаган балалар өчен. Ә бу очракта безнең әдәбият югала, татар теле гади сөйләмгә кайтып кала. Әгәр дә без татар балаларын шушы программа буенча укытабыз икән, бу – телебезне югалтабыз дигән сүз. Бала татар телен туган тел буларак тирәнтен өйрәнергә тиеш. Милли мәгариф мәсьәләләренә бик сак һәм игътибарлы булырга кирәк, – диде министрлыкның идарә башлыгы.

Марат Әхмәтов исә район башлыкларына милли мәгарифкә, тәрбия эшчәнлегенә тирән анализ ясарга кушты.

– Өч татар очрашса, русча сөйләшә башлый. Рус телен белү-белмәвебезне исәпкә алмыйбыз, вата-сындыра булса да, русча сөйләшергә тырышабыз. Кемгә нинди үрнәк күрсәтәбез без? Татарча сөйләшмәвебезгә рус теле түгел, үзебез гаепле. Телебезне үзебез аяк астына салып таптыйбыз, – диде ул. – Шушы проблемалар белән шөгыльләнәбез икән, беренче чиратта үзебезгә үрнәк күрсәтергә кирәк. Никадәр дәрәҗәлерәк, зуррак урындагы җитәкче үрнәк күрсәтсә, шуның кадәр әйбәтрәк. Абруйлы кешенең сүзе үтемлерәк була.

Ләйсән САФИНА

ИШ ЯНЫНА КУШ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яшәеш

Инде хәбәр иткәнебезчә, Татарстан Министрлар Кабинеты киләсе елга айлык акчалата түләү күләмнәрен билгеләде. 2023 елның 1 гыйнварыннан социаль түләүләр һәм субсидияләр 1,061 процентка арттырылачак. Сүз хезмәт ветераннарына, дәүләт бүләкләренә лаек булган кешеләргә, реабилитацияләнгән гражданнарга, ятим сабыйларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен тиешле социаль түләүләр турында бара.

Чаллыда яшәүче Айсылу Нургатина ире белән җиде ятимне әти-әниле иткәннәр. Алар дәүләт тарафыннан үз сабыйларына булган ярдәмгә бик канәгать.

– Без ятимнәрне акчасы өчен алмадык, – дип сүзен башлады Айсылу. – Хыялым күп итеп балалар үстерү иде минем. Әмма үземнекеләрне сөяргә насыйп булмады. 10 ел көттек. Мин исә күз яшьләремне тыеп, сабыр итәргә өйрәндем. Ятимнәр тәрбияләнүче бер приютка җомга саен күчтәнәч илтә башладым. Беренче килеп керүгә үк, нәни кызчык: «Әнием!» – дип, куеныма килеп сарылды. Шул көн тормышыбызны үзгәртте.

Айсылу белән Фоат башта ике кыз бала, аннан өч бертуган малайны тәрбиягә алалар. Әле менә ике ел элек тагын ике кызлы булып куйганнар. Балалар саны арта башлауга, акчасына кызыгасыз, диючеләр дә булган. Әмма Айсылу, ятим бала акчасы белән баеп булмый, ди.

– Һәр баланың акчасы өчен ай саен хисап тотабыз. Нәрсә алсак та, чекларын саклыйбыз. Сабый сөям дип, өйдә утырганыбыз юк. Икебез дә эшлибез. Шөкер, акчабыз җитә. Әлегә без дәүләттән бакчага йөрүче балалар өчен 9732 сум акча алабыз. Мәктәптә укучыларына 11222 сум түлиләр, – ди ул. – Кибеттәге бәяләрне күрсәгез, бу акчаның нәрсәгә җитәсен аңлап була. Ишле гаилә булгач, ризык та мулдан алына. Юл йөрү өчен дә ай саен акча бирелә. Анысы өчен дә бик рәхмәтлебез. Ул безнең гаиләгә зур ярдәм булып тора.

Айлык түләү күләме артучы кешеләр арасында хезмәт ветераннары да бар. Тукай районында яшәүче Миңнулла Мортазин бу хакта ишеткән инде. Әмма ул акчаны аз дип саный.

– Иш янына куш инде. Әмма әллә ни күп акча түгел бит ул. Гомер буе хезмәт ветераны булыр өчен күпме тырышып эшләргә туры килде. Бу акчаны пенсия белән бергә санагач, зарланып булмый инде. Әмма шулай да киләчәктә бу түләүнең тагын да артуын теләр идем, – ди ул.

Ә менә пенсионерлар өчен юл йөрергә дип бирелгән субсидиягә канәгать булмаган кеше тапмадым. Кемгә генә шалтыратсам да, яхшы сүзләр генә ишетергә туры килде. Баксаң, дәүләт ярдәме белән ай буе транспортта бушлай йөреп була икән. Шушы проездной аркасында тукталышта басып та торганыбыз юк, диләр.

– Берсеннән төшәм, икенчесенә утырам. Барасы җиремә дә җитешәм, – ди Казанда яшәүче Гөлсинә Шакирова. – Әле пенсиядә булсам да, эшләп йөрим. Мин бу ярдәм өчен бик рәхмәтлемен. Кайбер көнне акчага күчереп санап та карыйм. Миңа үзем яшәгән җирдән эш урынына кадәр ике автобус белән барасы. Акча түләсәң, бер якка гына 72 сумым китәр иде. Бер көнгә 144 сум дигән сүз бит ул.

Әлеге субсидияләр өчен Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы җаваплы. Министрлыкның матбугат үзәге җитәкчесе Рафаил Гыйниятуллин аларның ел саен индексацияләнүен искәртте.

– Әгәр кеше социаль ярдәмне моңа кадәр алган икән, ул аңа киләсе елда да автомат рәвештә килеп торачак. Әгәр бу түләүләргә яңа гына дәгъва кыласыз икән, аның төренә карап, тиешле оешмага барырга туры киләчәк. Гаризаларны йә Дәүләт хезмәтләре порталы аша, йә күпфункцияле үзәк аша тапшырып була, – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

Киләсе ел башыннан хезмәт ветераннарына һәм дәүләт бүләкләре булган кешеләргә ай саен 581 сум түләү каралган. 1941–1945 елларда тылда кимендә 6 ай эшләгән затларга – 867 сум, сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган гражданнарга 727 сум акча түләнәчәк. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган һәм гаиләгә тәрбиягә бирелгән ятим балаларга 10326 сум (мәктәпкәчә яшьтәге балаларга – 11907 сум) биреләчәк. Моннан тыш, ятим балаларга транспортта йөрүгә – 354 сум, пенсионерларга 581 сум күләмендә субсидия бирелә. Ялгыз аналарга ай саен 1014 сум акча түләнә.

АКЛАНСЫН ӨМЕТЛӘР

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ничек сайларга?

Тавыш бирү уңайлы һәм гади. Үзеңнең сайлау участогыңны белү өчен, республиканың Үзәк сайлау комиссиясе рәсми сайтына керергә һәм махсус бүлекчәне табарга гына кирәк. Адресны күрсәтү белән, система тавыш бирү өчен каралган участокны чыгарачак.

Моннан тыш Үзәк сайлау комиссиясенең «кайнар элемтә» телефон номеры эшли. 292-84-33 номеры буенча мөрәҗәгатьләрне җиткерергә мөмкин.

11 сентябрьдә участок комиссияләре иртәнге 7дән алып кичке 8гә кадәр эшләячәк. Тавыш бирү иҗтимагый контроль күзәтүе астында узачак, Татарстанның участок сайлау комиссияләре теләге булганнарны күзәтүчеләр сафына да кабул итәргә әзер.

Куркынычсызлык нихәлдә?

Сайлау көнендә тавыш бирүчегә үзе белән паспорт алып килү дә җитә. Әлбәттә, саклык чаралары турында онытмаска киңәш итәләр. Әмма монысы өчен борчылырга кирәкми: куркынычсызлык бар мәгънәдә дә тәэмин ителәчәк дип вәгъдә итәләр. Кыскасы, барысы да инде гадәтләнгән рухта оештырылачак.

Роспотребнадзор күрсәтмәләрен истә тотып, сайлау участокларында температура үлчәү, тавыш бирергә килүчеләргә битлек һәм кулларны дезинфекцияләү тәкъдим ителәчәк. Кирәк очракта, каләм дә бирәләр. Участок сайлау комиссиясе вәкилләре исә битлектән эшләячәк. Көн дәвамында бүлмәләрне җилләтү, җыештыру, дезинфекцияләү каралган.

Сәламәтлегенә бәйле рәвештә тавыш бирергә килә алмаган кешеләргә өйдән чыкмыйча гына да сайлауда катнашу мөмкинлеге бирелә. Моның өчен участок сайлау комиссиясенә алдан мөрәҗәгать итеп, бу хакта әйтергә кирәк. Гаризаларны 11 сентябрьдә дә көндезге сәгать икегә кадәр кабул итәчәкләр.

Фикер



Андрей КОНДРАТЬЕВ, Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе рәисе:

– Без сайлау кампанияләрен «зур» һәм «кечкенә» дип бүлмибез, безнең өчен һәркайсы мөһим һәм җаваплы. Бу – участок һәм территориаль сайлау комиссияләре өчен өстәмә хезмәт, сайлау системасының гражданлык активы өчен сынау. Һәр участокта күзәтүчеләр бар. Шунысын да әйтик: күзәтүче булырга теләүчеләр бик күп, бу юнәлештә аларны әзерләү буенча Татарстан Иҗтимагый палатасы белән эш алып барыла.
Тавыш бирергә килүчеләрнең күпме буласын алдан фаразлауның мәгънәсе юк. Беләбез бит: Татарстан һәрвакыт актив тавыш бирә. Тулаем алганда, Татарстанда сайлауга бару – күркәм традиция. Күпләр участокларга үзләре генә түгел, ә балаларын да алып килә, бу гадәтне яшь буыннарга тапшыра. Бу бик тә мөһим, чөнки тавыш бирү – җәмгыять гражданины тормышында җаваплы этапларның берсе булып тора.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүләре өчен Россия фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең фәнни җитәкчесе **Наумкин** Виталий Вячеславович; шагыйрь, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Гарифуллин** Дамир Хәйрулла улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Биология фәннәре докторы, «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Су биоресурслары һәм аквакультура» кафедрасы мөдире **Калайда** Марина Львовнага **«Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

ИЗГЕ ЮЛ

Чувашия Республикасының Козловка районындагы Кармыш авылында 22 ел элек башланып киткән бу бик матур традицион бәйрәм быел 20 нче тапкыр уздырылды. Ике ел билгеле сәбәпләр аркасында үткәрелмичә торганнан соң, ниһаять, кабаттан җыелыштык. Үзем бу авылдан булмасам да, дусларым монда күп булганга ел да кунак-тамашачы булып кайта идем. Ә быел исә оештыручылар миңа бәйрәмнең концерт-күңел ачу өлешен оештыру вазыйфасын йөкләделәр.

Быел бәйрәмне баянчы-гармунчылар белән авыл башыннан мәйданга җырлап төшүдән башладык. Халкыбызның иң оста баянчылары – Татарстанның атказанган артисты Ринат Вәлиев, Фәнзил Шәрифуллин һәм Илшат Хисаметдинов кайткан иде. Һәр йорт янына килеп, халыкны биеттек. Авылның хөрмәтле аксакалы Хәмзә абый тальян гармун белән үзенең ишегалдында каршы алды, бергәләп җырладык та. Аннары мәчет каршысында урнаштырылган элеккеге авыл муллалары турында стенд ачтык. Электән бу авылда 3 мәчет булган, ә хәзер шуларның барысы да берләштерелеп, авыл үзәгендә өч манаралы Аллаһ йорты тора.

Элек-электән килгән гореф-гадәт буенча, изге бәйрәмне Коръән аятьләре белән башлап җибәрдек. Кармыш авылында туып, балачактан ук чишмәләрдән шифалы су эчеп үскән, хәзерге вакытта Казанда имам-хатыйп булып эшләүче Фәрит хәзрәт Коръән укып, догалар кылып, халыкка матур һәм бик тә мәгънәле вәгазь сөйләде. Бәйрәмнең рәсми өлешен мәртәбәле кунаклар ачып җибәрде.

Мондый күркәм чараны иганәчеләрдән, ярдәм итүчеләрдән башка күз алдына да китереп булмый. Авыл өчен җан атып, һәрвакыт авылдашларын шатландырып-сөендереп торучы изге күңелле егет-кызларны да зурладылар.

Аннары сүз бабалары Кармыш авылыннан чыккан, La Primavera дәүләт камера оркестры сәнгать җитәкчесе, баш дирижер, музыкант, Тукай премиясе лауреаты, Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты Рөстәм Абязовка бирелде. Ул бу бәйрәмгә гаиләсе белән кайткан иде. «Мин авылга кайтуым белән бик бәхетле», – диде ул.

Татарстанның атказанган артисты Ринат Вәлиев үзенең төрле зурлыктагы гармуннарында уйнап, бөтен халыкны таң калдырды. Соңыннан без хәләл җәфетем Рамилә Хәйретдинова белән җырлар башкарганнан соң, бәйрәмнең махсус кунагы, Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинова өч сәгатьлек бик матур бәйрәм ясады.

Авылларыбызда мондый матур бәйрәмнәр ешрак узса иде, халкыбыз шулардан көч, илһам алып яшәсен иде. Бу – авылларыннан чыгып китеп, читтә яшәүчеләр елга бер булса да шундый бәйрәмнәргә авылларына кайтып, әрвахларга дога кылып, туган-тумачаларының, авылдашларының хәлләрен белер өчен бер сәбәп тә. Яшәсен татар авыллары, яшәсен татар халкы!

Туган авылларыбызга илтә торган юл – изге юл ул. Авылларга кайту – һәрвакыт онытылмаслык хәтер-хатирә. Чишмәләренең суы исә тәнгә сихәт, җанга шифа. Ул юл авылга тоташа, яшьлеккә алып кайта, балачак белән очраштыра.

Рамил ХӘЙРЕТДИНОВ

Без – сугыш чоры балалары

Әнием Рәхимә Әлки районының Төгәлбай авылы кызы иде, әтием Гыйззәтулла – Спас районының Ямбакты авылыннан. Алар бергәләп Казанда гомер итәләр. Әти бронь белән 1942 елга кадәр сугышка китмичә тора, аннан инде сугышка алына һәм озак та үтми аның хәбәрсез югалуы турында хат килә. Әни мине, тугыз айлык баланы, авылга әби-бабай янына кайтара, шулай итеп минем бөтен балачагым авылда үтте.

Кайда гына гомер итсәк тә, авыр еллар иде ул. Хәтерне яңарткан саен күңел сыкрый, елыйсы килә. Әни Казанга үзе янына бик алып китәр иде, әмма торырга урыны юк. Шулай да бик нык чирләп киткәч, ул мине үз янына алды. Ләкин һәркемнең үз хәле хәл, фатирга кертүче юк иде, без кем бераз якты чырай күрсәтсә, шуларда кунып йөрдек. Хәтта хәзерге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең подвалында да яшәгәнебез булды. Әни ашханәдә савыт-саба юа иде. Үсә төшкәч инде, мин заводка эшкә урнаштым. Әмма сугыштан соңгы авырлыкны әйтеп-сөйләп, язып бетерерлек кенә түгел. Без кичергәннәрне һичкемгә һичкайчан кичерергә язмасын.

Флүрә КОВЕЕВА

***

Балачагым – ачлык-ялангачлык әледән-әле хәтеремә төшеп тинтерәтә. Көнне төнгә ялгап, яшьлеген колхоз эшенә багышлаган Каенсар авылындагы дустым Рәеф Шакиров та ул елларны күз яшьләре белән искә ала. Күп кенә чордашларыбыз кебек үк ул да әтисез үскән. Әтисе сугыштан кайтмаган. «14 яшемдә «ДТ» тракторында плугарь идем инде мин, – дип сөйләгәне хәтердә, – аңарчы терлек көттем. Аннан комбайнга утырдым, «ДТ-75» тракторында да эшләдем. Эшләмәгән эшем калмады. Басуларда да мин аяк басмаган, трактор белән йөрмәгән җир калдымы икән? Миңа бит кайсы басуда эшләргә кирәклеген әйтүче булмады диярлек, үзем барып карый идем дә, басу өлгергәч, эшкә керешә идем. Тракторда бер ремонтсыз ун елдан артык эшләдем.

Сугыш чоры балалары менә шундый инде алар.

Рафаил БӘЙРӘМОВ.
Әтнә районы

***

«Без – сугыш чоры балалары» дигән әйтем тормышта әледән-әле очрап тора. Әмма безгә карата игътибар зур, димәс идем. Әллә ни зур булмаган пенсиягә җан асрыйбыз. Әле ярый анысы бар, дип шөкер итәргә генә кала инде… Иң авыр чорда үскәннәргә, шуннан соң илне тергезүдә тырышлык куйганнарга игътибар да тиешенчә булса, яхшы булыр иде дә бит…

Хәбибулла КӘРИМОВ.
Казан

ҖАЙЛЫ, ҖИТЕЗ ЗӨФӘР

Иҗади дустым Зөфәр Сафин янына «Татар баянчылары» исемле китабым дөнья күргәч, шатлыгымны уртаклашырга дип бардым.

«Мөмкин булса, култамга белән бирә алмассызмы икән?» – диде ул. Бик теләп, ризалашып язып тапшырдым: «Зөфәр дустым, китабымны сиңа чын күңелдән бүләк итәм. Зөфәрләр күп, Сафиннар да. Зөфәр Сафин исә бер генә… Аннан безнең фамилияләр дә бер үк хәрефтән – «С» хәрефеннән башлана». Ике югары уку йортын тәмамлаган сәнгатькярне китап шактый уйландырган. Укып чыккач, ул миңа түбәндәгеләрне «сайрады»: «Кирам абый, синең эчеңдә кара юк, әгәр дә син кара эчле булсаң, баянчыларны мактап түгел, әгел хурлап кына йөрер идең… Кыскасы, син – киң күңелле, кешеләргә ихтирамлы, игътибарлы шәхес. Эчеңдә кара юк…»

Шуннан соң без тагы да бер-беребезгә якынайдык. Кайберәүләр умырып-каерып акча эшләп йөргән заманда, без өчәү – язманың герое, аның хәләл җефете Наилә ханым һәм мин мәктәпләрдә балаларга мәдәният, музыка өлкәсендә аң-белем бирү белән шөгыльләндек. Бергәләп музыкаль табышмак ясадык. Монда халык җырлары, классик композиторларыбыз әсәрләре, кинофильмнардан, телевизион тапшырулардан музыка, эстрада, заманча яңгырашлы көйләр һ.б. бар иде. Татарча әйткәндә, егет кешегә 70 төрле һөнәр дә аз була торгандыр инде. Менә шуларны күздә тотып эшләгән музыкаль табышмак иде ул. Ул кемгәдер ошар, кемгәдер юк. Һәрхәлдә, зыяны тимәс.

Әйткәнемчә, шушы гамәлләребез белән киләчәк буынга күпмедер ярдәм иткәнбез икән, халкыбыз өчен ниндидер эш күрсәткәнбез икән, азмы ул, күпме – без шуның белән бәхетле.

Зөфәрнең кешелек сыйфатларына да бераз тукталып узыйм әле. Беркөнне миңа шалтыраттылар: җырчыбыз чирләгән, тиз генә алмаш табарга кирәк. Телефоннан Зөфәргә: «Концерт костюмнарыңны ал да тиз генә миңа кил», – дидем. Ул тиз генә килеп тә җитте.

Укытучылар көнен билгеләп үтү тамашасына да Зөфәрне чакырдым. Зөфәргә кеше белән аралашу, уртак тел табу һ.б. сыйфатлар хас. Аның белән эшләү уңайлы, ул – җайлы кеше.

«Татарстан» радиосына Наилә һәм Зөфәр Сафиннар белән берничә җыр яздырдык. Аккомпанементын миңа уйнарга туры килде. Ә хәзер инде шул язмаларны «алтын фонд» диләр. Шулайдыр, без – бу фани дөньяның кунаклары гына. Кунак, дигәннән, кунак ул килә дә китә. Ә язмалар кала… Алар мәңгелек…

Кирам САТИЕВ,
Татарстанның халык артисты

Шатлыкта үтсәче гомерләр!

Ни генә дисәң дә,
Уфтанып йөрсәң дә,
Кайтмый шул үткәннәр,
үткәннәр.
Якты эз калдырып,
Дөньяны яктыртып,
Яшисе иде әле бергәләп.

Картаймасын бер дә,
Яшь калсын күңелләр,
Биеп-җырлап яшик гомергә.
Искә алырлык булсын
Үткәннәр, үткәннәр.
Шатлыкта үтсәче гомерләр.

Үтмәсен әле, дип
Торсак та уйланып,
Көннәр бик тиз үтеп китәләр.
Аяклар йөрерлек,
Күзебез күрерлек
Бирсен иде Ходай гомерләр.

Әлфия ШӘФИГУЛЛИНА.
Казан

АҢЛАШАБЫЗ, ФАЙДАСЫН КҮРӘБЕЗ

Минем кәҗәләр, сауганда, «тик торыгыз» дигәнне аңламый башлады. Бервакыт шулай: «Стой!» – дип кычкырып җибәрдем. Ходайның рәхмәте, ниндидер тылсымга ия сүз булып чыкты, кәҗәләрем кымшанмый, ничек баскан – савып бетергәнчегә кадәр шулай торалар. Бер кәҗәм, күз-колак булмасаң, тавык йомыркасын эчәргә гадәтләнеп китте, үләннәрнең дә очын гына ашый, суның да чистасын гына эчә. Кеше акыллары бардыр, диярсең. Кайчакларда: «Туйдым сездән», – дим дә уйланып куям: менә шул йомырка эчә торган кәҗәм айга йөз литрдан артык сөт бирә, яз көне мамыгы белән дә сөендерә. Тормыш алып бару өчен файда бит. Шулай итеп, татарчалы-русчалы да аңлашабыз, өстәлебездән сый-нигъмәт тә, башка кирәк-ярак та өзелми. Яшәсен кәҗәләрем!

Мәүлидә ГАЙСИНА.
Минзәлә районы

Догачыбыз, яклаучыбыз

Август башында Казанның «Ярдәм» мәчете җәмәгать эшлеклесе, журналист Әлмира Әдиатуллинаны искә алу мәҗлесе оештырды. Вафатына бер ел тулуга багышланган табынга апабыз белән күп еллар бергә эшләгән каләм ияләре, милләтем-динем дип кайгырткан галимнәр, дин әһелләре, туганнарыбыз җыелды.

Байтак еллар апа белән бергәләп дин-ислам темаларын яктыртучы журналист, XX гасыр ахырындагы атаклы дин әһелләре хакында тарихи китаплар авторы Вәсилә Рәхимова апабыз турында «Фидакарь мөслимә» дигән тарихи-публицистик очерклар китабын тәкъдим итте. Рәхмәт яугыры, Казанның тарихи Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы Мансур хәзрәт Җәләлетдин һәм «Ярдәм» мәчете имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Баязитов апабыз хакында китап чыгару идеясен азагынача җиткереп, бастырып өлгерттеләр һәм барыбызга тараттылар. Искә алу мәҗлесендә һәркайсыбыз җылы хатирәләргә бирелдек. Һич онытылмас истәлекләрем белән «ВТ» аша уртаклашасы иттем.

Гаиләбездә Әлмира апа – иң олысы, мин – төпчеге. Яшь аермасы – 17 ел. Мин туганда инде ул бәхет эзләп, авылдан чыгып киткән. Хатирәләргә килгәндә, аны барыбызның да сагынып көтеп алуыбызны беләм. Ике арада хатлар йөри иде. Казан тикле Казанда яшәүче апага туганнарча мәхәббәт, тартылу шулкадәр көчле иде, минем аңа хат язасы килде. 3–4 яшьләрдә булганмындыр. Үземнән олыракларга: «Мине язарга өйрәтегез, апага хат язар идем», – дигәч, кулыма кәгазь белән карандаш тоттырдылар. Шуңа төрлечә сызгалап, «үземчә» хат язуымны хәтерлим. Мин генә түгел, апаның кайтуын бөтен авыл баласы көтеп ала иде. Гаиләбездә дә, урамыбызда да бәйрәм була: әле бер-бер уен оештыра, әле Казан турында мавыктыргыч итеп сөйли, әле кайдандыр фотограф табып, барыбызны җыеп фотога төшерә, мәш килә. «Азат хатын» журналында эшли башлагач, апа һәр кайтуында күрше-тирә авылларга чыгып, журнал эшчәнлеге белән таныштыруны гадәткә кертте. Безнең якта «Азат хатын»ны алдырмаган гаилә юк иде. Якташларым Әлмира Әдиатуллинаның да тырышлыгы кергән басманы озак еллар яратып укыдылар.

Шөкер, без үскәндә өстәлебез мул булды. Әти-әни, без нык булып, чын кеше булып үссеннәр дип, үзләре белгәнчә тырыштылар. Бу бала үсә-үсә кая барыр, нинди һөнәр сайлар, дип уйлау булгандырмы, әйтү авыр. Ә менә Әлмира апабызның кайгыртуы, һәрберебезнең мөмкинлекләрен чамалап, юл күрсәтүе, киңәш бирүе зур роль уйнады. Дүртебез дә шушы апа аша үттек. Тормышта үз юлыбызны салуыбызда ул хәлиткеч урын тота. Ападан соң Казанга юлны 1946 елгы олы абыебыз Ирек салды.

Мин Чаллыда милициядә эшләдем. Гомеремнең 33,5 елы тәртип саклап үтте. Апаның очрашкан саен әйткән сүзе, киңәше: «Энем, гадел бул, кешеләрне җәберләмә, сабыр бул!»

Ул туры сүзле иде. Алдан күрүчәнлеге дә көчле. Еллар үткәч, бу һөнәр белән кая барып җитәсен дә чамалый. Кайгыртуы таләпчәнлеге, кырыслыгы белән үрелгән. Күреп тора: әз генә йомшаклык күрсәтсәң, кызгансаң, ул күрсәткән юлдагы нәтиҗә ераклашачак, нәтиҗәгә ирешеп булмаячак. Һәрберебезне контрольдә тотарга ничек көче җиткәндер, кайдан вакыт тапкандыр, дип, хәзер торып-торып гаҗәпләнәбез.

Еллар үткән саен, туганнар белән шул хакта искә алабыз: кара әле, ул бит безгә гомере буена юл күрсәтүче, кайгыртучы һәм догачы олы апабыз булды! Хәтергә уелган вакыйгалар байтак. 1975 елның октябрь ахырында Казаннан Илеш районына – үзебезнең туган якларга Әлмира апа, Расих җизни белән бергәләп кыз алырга кайтуыбызны һич онытасым юк. Юллар начар, ул елны кары да бик иртә ятты, күп яуды. Кәләш янына туй көнне генә кайтып җиттек. Яшьлек! Ник бер зарлану булсын?! Безнең апа зарлануны белдеме икән ул?! Кыз ягында туйны гөрләтеп уздырып килүгә, Әлмира апа, кияү ягында туй ясыйбыз дип, туганнарны җыюны үз өстенә алды. Мәҗлесне үзе алып барды. Бик матур узды туебыз. Менә шундый апаны онытып буламы?!

Үзе бик тырыш иде. Җизни белән бакчасын да тоттылар, һәммәбезгә булышырга да өлгерделәр. Шулай да матди байлык артыннан куучы булмады апа. Җәмәгать эшләре уртасында кайнап, үзен кайгыртмады. «Апа, үзеңне дә карарга вакыт җиткән бит инде», – дигәнгә ул: «Үземнеке каралыр!» – дип куя иде. Бик көчле хатын-кыз булды. Әйткәнен азагынача җиткерә. Татар халкы аны иҗтиһад иткән кеше һәм бик күп башлангычларга кыю юл ярган җәмәгать эшлеклесе буларак истә калдырачак.

Робис ГАТИАТУЛЛИН.
Чаллы

Белдерү

Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәр

Күчемсез милек объектларына карата (түбәндәге территориядә урнашкан: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Шигали авылы җирлеге, кварталларның кадастр номерлары 16:33:181627, 16:33:181628), 24.05.2022 ел, № 9222000153-ОК дәүләт контракты нигезендә, комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Мәнфәгатьле барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең төгәлләнүе турында хәбәр итәбез. Алар белән килештерү комиссиясенең эш адресы (Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Иске Шигали авылы, Үзәк ур., 45 й., (тел.: 8(84367) 31924) буенча

яки Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (Комплекслы кадастр эшләре заказчысының – https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы хакимиятенең (территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте башкарма органының – https://pestreci.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (кадастр учеты органының – https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында танышырга мөмкин.

Аларга карата 16:33:181627, 16:33:181628 кадастр кварталлары территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2022 елның 23 сентябрендә 13 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Иске Шигали авылы, Үзәк ур., 45 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2022 елның 2 сентябреннән 2022 елның 23 сентябренә кадәр һәм 2022 елның 23 сентябреннән 2022 елның 27 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә һәм әлеге каршы килүне җибәргән зат турында мәгълүматларны, шулай ук фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булганда), шулай ук милекче адресын һәм (яки) милекченең электрон адресын, шәхесен раслаучы документы реквизитларын, җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны белән килешмәве сәбәпләре нигезләнешен, җир кишәрлегенең кадастр номерын (булганда) яки территориянең карта-планы проекты нигезендә җир кишәрлеге билгеләнешен үз эченә ала. Әлеге каршы килүләргә аны җибәргән затның мондый җир кишәрлегенә хокукын раслаучы документлар күчермәләре яки мондый җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче яки раслаучы башка документлары, шулай ук мондый җир кишәрлеген булдыруда чикләрнең урнашу урынын билгеләүче документлар (билгеләгән документлар булганда) кушып бирелергә тиеш.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Язмыш

«Арабызга хыянәт кермәде»

«Шакирҗанны яшен суккан!» Бу хәбәр 45 хуҗалыклы Түбән Шубанның астын өскә китерә. Олысы-кечесе Шакирҗаннарга – авылның Дүче башына йөгерә. Барысының да кулында көрәкләр. Алар арасында Гөлирам да була. Тик ул чакта кыз әле берничә елдан шушы егетнең үзе өчен бик якын кешегә әйләнәсен белми.

…Унҗиде-унсигез яшьләрдәге Шакирҗанда яшәү билгесе калмаган була. Аны бакчага алып чыгып… күмәләр. Әле өч таза бәдәнле ир-ат өстенә менеп тә утыра. Тәне балчыкка әйбәтләп тиеп торсын, «яшене җиргә күчсен» өчен. Фән бу алымның ялгыш булуын расласа да, Шакирҗан исән кала. «Кинәт аңына килде дә, өстендәге әзмәвердәй өч ир-атны, балчыкларны як-якка селтәп атып, сикереп торды, анда әллә нинди көч барлыкка килгән иде, үзен кая куярга белмәде. Аннан аңа кара сыер сөте эчерделәр дә больницага алып төшеп киттеләр. Анда да озак яткырмадылар», – дип искә ала ул көннәрне Гөлирам апа.

– Безнең өй чишмә буенда иде. Кинәт бик каты яңгыр ява башлады, чит кешеләр дә безгә керде. Яшен сукканда өйдә кеше күп иде. Мин морҗа буенда идем, пешмәгәнмен, уң якка бик нык бәргән иде. Ул чакта зыяны беленмәсә дә, еллар үткәч, үзен шактый сиздерде. Ул яшен бик тә могҗизалы булды: бишектәге туганыма берни булмаган, авылдаш малайның аяк киеме эчендә бармагы пешкән иде, өй янмады, түбә юк, морҗа тетелеп беткән… Ул өйдә яшәрлек булмады инде. Буш торган конторга күчендек, – дип сөйли Шаркирҗан абый.

Бүген инде Гөлирам һәм Шакирҗан Шәриповлар – Балтач районының Түбән Шубан авылындагы иң өлкән, хөрмәтле кешеләреннән. 61 ел тату, тигез гомер кичереп, бүген уллары һәм киленнәре тәрбиясендә бәхетле картлык кичерәләр. Хәтерләре, аң-зиһеннәре сөбханаллаһ дип әйтерлек. Авылның элеккесен дә, хәзергесен дә бик әйбәт беләләр. Алар белән үткәннәргә кайтып килдек.

– Клубка Югары Шубанга менә идек. Кызлар бергә кайтабыз. Арттан егетләр куып җитә дә кемне ошата, шуны озата бара. 1959 ел иде. Безне Шакирҗан куып җитте, сөйләшә киттек һәм шуннан очраша башладык, – дип искә ала Гөлирам апа. – Шул елның 27 декабрендә мине Югары Шубан клубына мөдир итеп куйдылар. Ике еллап эшләгәч, егерме бер яшемдә тормышка чыктым. Хәзерге кебек туйлап түгел инде, эштән ат арбасына утырып, Шакирҗаннарга кайттым. Өйдә әни белән әби генә калды. Ярый әле квартирантыбыз бар иде. Шуңа ышанып киткәнмендер инде. Шакирҗан гомер буе әниләрдәге бөтен ир-ат эшен эшләп, аларга бик күп кадер-хөрмәт күрсәтте. Әни аңа бик рәхмәтле иде, соңгы сүзе дә «кияүгә каршы эндәшмә» булды.

Күкрәк баласы белән тол калган (ире 1942 елда Смоленск тирәсендә һәлак булган), ялгыз башка тормыш итүнең бар михнәтен татыган әни кешенең соңгы сулышында да киявенә булган хөрмәтен-рәхмәтен белдерүе гаҗәп түгел. «Әни әтине гомере буе көтте. Үләр вакыты җиткәч кенә өмете өзелде…»

Шакирҗан да – әтисез үскән бала, ятимлек аларны бер-берсенә бик тә якынайта. Гөлирам бу гаиләгә җиденче кеше булып килеп керә. «Әни дә, апайлары, балалар да мине бик якын итеп каршы алдылар, бик килешеп, тату яшәдек», – дип искә ала ул елларны.

Гомер буе клуб-китапханәдә эшли Гөлирам апа. Үз авылларында да, башка авылга йөреп тә эшләргә туры килә. Ул чорда мәдәният хезмәткәрләре өстенә бик күп җәмәгать эшләре йөкләнә. Гөлирамга да берсе өстенә берсен кушып кына торалар: агитатор, стена газетасы редакторы, агитколлектив җитәкчесе, ревкомиссия рәисе… Барысын да булдырып эшли ул.

Шакирҗан абый – йортта берләнбер ир-ат заты булып, бала чактан авырлык күреп үскән кеше. «Уникe яшьтә урман кисәргә җибәрделәр, безгә ничек ат ышанып тапшырдылар икән?» – дип аптырый ул бүген. Унике яшьлек малай-шалай ничек урман кисә алсын инде, дип аптырамый, әнә шулай, ничек атны ышанып тапшырдылар икән, ди. Гомер буе тыныч кына, алдына карап эшләгән егетне кайда эшләсә дә, бик яраталар. КЗС, АВМнар әле колхоз тормышына яңа килеп кергән чорда, аларны аңа ышанып тапшыралар. Фермада ат белән дә эшли, гаражда слесарь булып та күп еллар техникаларга икенче сулыш өрә.

– Мин аңа бик рәхмәтле, – ди Гөлирам апа. – Гомере буе хөрмәтләп яшәде. Көнләшмәде. Мин бит гел кеше арасында йөрдем, кичләрен дә эшләргә туры килде. Арабызга хыянәт кермәде. Гел гаиләсе өчен, безне кайгыртып яшәде. Шушылай озак еллар бергә яшәвебезнең, тигез картаюыбызның сере дә әнә шунда. Мин хастаханәдә авырып ятканда, ковид дип, балаларны сакларга кертмәделәр, «Ничек тикшеренергә кушсагыз, шулай тикшеренәм, карчыгым янына кертегез», – дип өзгәләнгәч, аны керттеләр, 87 яшендә мине саклап ятты әле ул… Юкса үзе дә – 2008 елда инфаркт кичергән кеше бит…

Шакирҗан абый да бик рәхмәтле җәмәгатенә. Кычкырып әйтмәсә дә, күзләре тулы наз аның. Матур булып картая алуында кадер-хөрмәттә яшәткән карчыгының да өлеше бихисап лабаса. Шакирҗаны каты авырып киткәч, әнә Гөлирам апа әбисе өйрәткән догаларны исенә төшерә, намазга баса.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Автор фотосы

ПӘРДӘЛӘР АЧЫЛА

ТЕАТРЛАР ЯҢА СЕЗОННЫ БАШЛЫЙ

kamalteatr.ru

Тиздән күбебез яктылыкка, нурга илтә торган сукмакларны таптый башлар. Театрларның җәйге ялы тәмам, барысы да яңа сезонга әзерләнә. Өлгеррәкләре театраль сезонны ачып та җибәрде, инде премьера белән «сыйлаучылар» да бар. Яңа сезоннан ниләр көтәргә?

Камал театры

Камаллылар 117 нче сезоннарын, гадәттәгечә, данлыклы «Зәңгәр шәл» белән ачып җибәрде. Быел иртәләделәр: Булат 9 сентябрьдә үк «кайтты». Моның сәбәбен яңа сезонга багышланган матбугат очрашуында Камал театрының директоры Илфир Якупов аңлатты:

– Казан да, вакыт та үзгәрә. Башкалабызда туристлар агымы арта, шуңа күрә сезонны бераз алданрак ачарга тәкъдим иттем. Артистлар ялларыннан 8 августта чыкты. Республика көне уңаеннан, җәй азагында дүрт спектакль күрсәтелде, – диде ул.

Камал театрында яңа сезонда биш премьера күрсәтергә ниятлиләр. Беренчесе 22 һәм 23 октябрьдә булачак. Коки Митани атлы япон драматургы әсәренә нигезләнеп, режиссер Айдар Җаббаров «Көл» спектаклен чыгара. Спектакльдә бары ике актер – Эмиль Талипов һәм Алмаз Борһанов кына катнаша. Тамашаны театрның Кече залында күрсәтәчәкләр.

5, 6 һәм 7 ноябрьдә театр Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр» әсәре буенча куелган спектакль тәкъдим итәчәк. Театрның баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев сүзләренчә, камаллылар 3,5 сәгать бара торган ике тәнәфесле спектакль әзерли. Сүз уңаеннан, Мәхмүт Галәүнең әлеге күренекле әсәрен сәхнәгә чыгару – баш режиссерның күптәнге хыялы. Гомумән, яңа сезон татар театрлары баш режиссерларының күптәнге ниятләрен тормышка ашыруы белән истә калыр, ахры. Нигә икәнен соңрак аңларсыз.

Декабрьнең соңгы көннәрендә Айдар Җаббаров Әмирхан Еники әсәре буенча «Рәшә» спектаклен куярга ниятли.

Үзебезнекеләрдән тыш, Камал театрының яңа сезоны премьералары исемлегендә бурят режиссеры Сойжин Жамбалова спектакле дә бар.

Яңа сезонның тагын бер премьерасын Рамил Гәрәев куячак. «Яңа татар пьесасы» лабораториясе кысасында Булат Минкин иҗат иткән, 1920 нче еллардагы ачлык чорына багышланган «Татар trip» пьесасын сәхнәләштерәчәкләр.

Билет бәяләренә килгәндә, әлегә әллә ни үзгәрешләр сизелми. Театрның рәсми сайты мәгълүматыннан күренгәнчә, билет бәясе – 400–1500 сум. Шулай ук билетларны «Пушкин картасы» белән дә алып була.

Тинчурин театры

Тинчурин театры 89 нчы сезонын һәрвакыттагыча 15 сентябрь – Кәрим Тинчуринның туган көнендә ачып җибәрәчәк. Быел күренекле драматургның тууына 135 ел икән. Шуңа да театр труппасы бу сезонга ныклап әзерләнә. Тинчурин театры директоры Фәнис Мөсәгыйтов сүзләренчә, сезон ачыласы көнне драматургка багышланган төрле флешмоблар, лекцияләр, квестлар уздырырга ниятлиләр.

Һәм шушы ук көнне театрда Кәрим Тинчуринның иреклe тәрҗемәсе буенча эшләнгән «Хан кызы Турандык» трагикомик әкиятен күрсәтәчәкләр. Спектакльне шулай ук 16, 30 сентябрь, 14, 29 октябрь көннәрендә дә карап булачак. Сүз уңаеннан, әлеге әсәр тәүге тапкыр 1918 елда ук сәхнәләштерелә. Ул чакта Турандыкның йөрәген яулап алырга омтылган Хәләф ролен Кәрим Тинчурин үзе уйнаган. Бу юлы әсәрне Венгриядән килгән татар егете Сәрдәр Таһировский куячак. Узган сезонда ул үзенең Казанда узган балачак елларына багышланган «Ядәч! Исемдә!» спектаклен куйган иде. Тинчурин театры күңеленә хуш килгән, күрәсең.

Тинчурин театры сәхнәсендә баш режиссер Туфан Имаметдинов та ике премьера белән «сыйларга» вәгъдә итә. Баш режиссерның һаман «теле ачылмау»га бик аптыраганнар иде инде узган ел. Менә бит!

Беренчесе – «Соф(т) татарча» лабораториясе кысасында язылган әсәр. Аны режиссер һәм фотограф Рәмис Нәҗмиев язган. Апуш атлы робот та катнашачак, дип вәгъдә итәләр. Көннәре генә билгесез.

Туфан Имаметдинов яңа сезонда күптәнге хыялын да тормышка ашырачак. Баш режиссер «Идегәй» дастанын сәхнәләштерергә ниятли. Бу ниятен тормышка ашыруның бик катлаулы булуын да яшерми. «Идегәй»не куяр өчен, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан, Тинчурин театрына грант бирелгән иде. Насыйп булса, барырбыз да, күрербез дә.

Билет бәяләре 300–1000 сум аралыгында тирбәлә.

Кариев театры

Кариев исемендәге Яшь тамашачы театрында яңа – 35 нче сезон 30 сентябрьдә ачылачак. Сезонны узган ел премьерасы – «Йосыф» спектакле белән башлап җибәрергә ниятлиләр. Ә аңа кадәр театр каршындагы мәйданчыкта «Яралу» дигән музыкаль-хореографик перформанс булачак.

Премьераларга килгәндә, беренчесе 14 октябрьгә билгеләнгән. 33 нче сезонда Мостай Кәримнең «Озын-озак балачак» әсәрен сәхнәләштергән һәм тамашачы мәхәббәтен яулаган Илсур Казакбаев, Уфа каласыннан килеп, «Ромео һәм Джульетта»ны куячак.

Кунак режиссерлар арасында Буа театрыннан Тимур Кулов та бар. Ул яңа сезонда Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары»н сәхнәләштерәчәк.

Билет бәяләре – 250 сумнан алып 600 сумга кадәр.

Әтнә театры

Әтнәлеләр 106 нчы сезоннарын ачарга өлгерде инде. Беренче премьералары да булып узды. Чыңгыз Айтматовның «Ак пароход» драмасын тәкъдим итте алар. Бу көнне театр тагын бер сөенечле яңалык җиткерде – хәзер аларның рәсми сайтларында үз радиолары эшли.

Быелгы сезондагы спектакльләр арасында Илгиз Зәйниевнең узган ел бик җылы кабул ителгән «Хыял йорты» да бар. Театр белгечләре «Алмачуар», «Беренче мәхәббәт» пьесаларын да карарга киңәш итә. Билет бәяләре дә кулай монда: 200–500 сум.

Әлмәт театры

Әлмәтлеләр 78 нче сезоннарын 6 октябрь көнне Илгиз Зәйниевнең «АХ, яки Мәхәббәт элмәге» комедиясе белән ачарга җыена. Премьераны 7се көнне дә күрсәтәчәкләр.

Сүз уңаеннан, Әлмәт театры труппасы 22 сентябрьдә Камал театры сәхнәсендә «Җил артыннан» спектаклен куячак. 26 ноябрьдә Казан тамашачысы Гаяз Исхакый әсәре буенча режиссер Айдар Җаббаров куйган «Ул әле өйләнмәгән иде» спектаклен карый алачак. Яңа елдан соң әлмәтлеләр Зөлфәт Хәкимнең «Ана җыры» әсәре буенча куелган спектакльләрен алып килергә ниятли.

Билет бәяләре – 400–600 сум.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

6+

almetteatr.ru

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казанның «Курган» зиратында танылган татар язучысы Әхәт Гаффар каберенә истәлек ташы куелды. Язучыны искә алырга, рухына дога кылырга мәдәният, дин әһелләре, якыннары җыелган иде.

– Арабыздан киткән шәхесләребезне барлау, иҗатларын киләсе буыннарга тапшыру – һәрберебезнең дә бурычы. Бүген без татар әдәбиятының зур шәхесләренең берсе Әхәт Гаффарны искә алабыз. Ул үзеннән соң бик зур иҗади мирас калдырды. Туган телен, илен, халкын, хезмәтен бик яратып яшәгән әдәпле, тыйнак кеше иде. Әхәт абый һәрберебез күңеленә үзенең кешелеклелеге, ихласлыгы белән кереп калды. Шушы эшебез аның рухына дога булып барсын, рухы шат булсын иде, – диде Татарстан Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерү фонды башкарма директоры Нурия Һашимова.

Сиксәненче елларда яшь татар әдәбияты турында сүз чыкса, Әхәт Гаффар исемен әйтмичә калмыйлар иде. Татарстанның халык язучысы Равил Фәйзуллин якташын әнә шулай дип искә алды.

ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛ

ЯЗУЧЫ ӘХӘТ ГАФФАР КАБЕРЕНӘ ТАШ КУЕЛДЫ

– Ул бөтен тормышын иҗат итүгә, татар әдәбиятына хезмәт куюга багышлады. Әдәбиятыбызда зур якты эз калдырды. Кеше буларак холкы, бәлки, шома да булмагандыр, тик аның кешеләргә энә кадәр дә хөсетлеге булмады. Кешеләргә күләгә төшермәде, аның күңеле бай иде, – диде язучы.

Таш кую мәрасименә язучының якташлары да килгән иде.

– Балык Бистәсе – милләтебезгә бик күп бөек шәхесләр бүләк иткән төбәк. Шулар арасында күренекле язучыбыз Әхәт Гаффар да бар. Әхәт абый үзенең туган нигезе белән бервакытта да элемтәсен өзмәде. Читтә яшәсә дә, безнең чакырганны көтмичә, һәрвакыт кайтып җитә иде. Безнең күңелләрдә йөзендәге елмаюы, эчкерсезлеге, гадилеге белән матур эз калдырды, – диде Балык Бистәсе район башлыгы урынбасары Фирдания Бәдретдинова.

Язучының бертуган энесе Рәкыйп Гаффар тормышын журналистика белән бәйләвендә абыйсының өлеше зур булуын әйтте.

– Мин иң бәхетле журналистларның берсе булдым. Университетта укыганда, ике абыем да «Социалистик Татарстан» газетасында эшли иде. Мин читтән торып укый, Чаллыда эшли идем. Кышкы имтиханнарга килгәч, Әхәт абый миңа бер генә сүз әйтте. «Кеше буласың килсә, көндезгегә күч», – диде. Иҗат кешесенә чын бәяне киләчәк буыннар бирә. Халык күңеленә кереп калу өчен, Әхәт, Равил абыйлар кебек көн-төн эшләргә кирәк. Кеше күңеленә керә торган сүз әйтә белүнең иң зур бәхет икәнен менә мондый очрашулар вакытында аңлыйбыз, – диде Рәкыйп Гаффар.

Әхәт Гаффарның кызы Ләйлә Гаффарова әтиләрен искә алырга килүчеләргә һәм таш куярга ярдәм итүчеләргә рәхмәт сүзләре җиткерде. Әтисенә бәйле истәлек белән дә уртаклашты:

– Бәләкәй чакта, бүгенге кебек үк яңгырлы көндә, әти белән каядыр бара идек. Юл шундый озак, мин зарлана башлагач, әти миңа: «Бу көнне Аллаһы Тәгалә яратты. Бу – аның безгә биргән бүләге. Бүгенге көн беркайчан да кабатланмаячак», – диде. Шул сүзләре күңелемә шулчаклы кереп калды: мин шуннан соң һәр көнне зур бүләк итеп кабул итәм, һәр туган көнгә сөенеп яшим. Сөмбел белән без – әтинең һәм әнинең юлларын дәвам иттерүчеләр. Кешене башка кешеләр искә төшереп торса гына, аның турында истәлек яши, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6708 данә
Гомуми тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 332

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+